ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17 декабрь, 2015 ел № 4/7

Аерым муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре хезмәтләренә түләү өлкәсендә Шәһәр Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 21 октябрендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 18 октябрендәге «Татарстан Республикасының дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү арту турында» 768 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 791 санлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 30 октябрендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 14 июнендәге «Хезмәтләренә түләү Бердәм тариф челтәре буенча хисапланучы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хаклары арту турында» 477 санлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 812 санлы Карары, шәһәр Уставының 28 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. 2015 елның 1 октябреннән хезмәтләренә түләү шартлары Шәһәр Советының түбәндәге карарлары белән җайга салынган муниципаль учреждениеләр һәм муниципаль оешмалар хезмәткәрләренә вазифаи окладка, стимуллаштыру характерындагы түләүләргә (башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләрдән һәм премия түләүләреннән тыш) 10 процент күләмендә өстәмә түләү билгеләргә:

1) Шәһәр Советының 2012 елның 20 декабрендәге «Шәһәр Советының 2010 елның 26 августындагы 53/7 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең аерым муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре өчен хезмәткә түләүнең яңа системасы турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында» 22/8 санлы Карарының 6 пункты;

2) Шәһәр Советының 2015 елның 15 апрелендәге «Хезмәткә түләүнең яңа системасы кертелгән муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре өчен хезмәткә түләү шартларын билгеләү турында» 39/8 санлы Карары.

2. Шәһәр Советының 2010 елның 26 маендагы 50/5 санлы Карары (Шәһәр Советының 2010 елның 15 июлендәге 52/5, 2010 елның 26 августындагы 53/7, 2011 елның 27 гыйнварендәге 8/4, 2011 елның 25 августындагы 13/7, 2011 елның 27 октябрендәге 14/7, 2012 елның 20 декабрендәге 22/17, 2013 елның 31 октябрендәге 27/9, 2013 елның 19 декабрендәге 28/9, 2014 елның 10 июлендәге 31/6, 2014 елның 9 декабрендәге 35/7, 2014 елның 23 декабрендәге 36/5, 2015 елның 15 апрелендәге 39/7, 2015 елның 22 октябрендәге 2/12 санлы Карарлары редакциясендә) белән расланган муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү тәртибе һәм шартлары турында Нигезнамәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «6. Учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү буенча Бердәм тариф челтәренең тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлары):

| Бердәм тариф челтәренең түләү дәрәҗәләре | Тариф коэффициентлары | Тариф ставкалары (окладлары), сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | 1,0 | 2239 |
| 2 | 1,047 | 2344 |
| 3 | 1,09 | 2440 |
| 4 | 1,142 | 2557 |
| 5 | 1,268 | 2839 |
| 6 | 1,407 | 3150 |
| 7 | 1,546 | 3461 |
| 8 | 1,699 | 3804 |
| 9 | 1,866 | 4177 |
| 10 | 2,048 | 4585 |
| 11 | 2,241 | 5018 |
| 12 | 2,423 | 5426 |
| 13 | 2,617 | 5860 |
| 14 | 2,813 | 6298 |
| 15 | 3,035 | 6796 |
| 16 | 3,260 | 7299 |

| | | |
|---|---|---|
| 17 | 3,511 | 7862 |
| 18 | 4,499 | 10074 |

Искәрмә: җитәкче урынбасарының тариф ставкасы (оклады) күләме тиешле җитәкченең тариф ставкасыннан (окладыннан) 1-2 дәрәҗә түбәнрәк билгеләнә.»;

2) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Хезмәтләренә түләү Бердәм тариф челтәре нигезендә хисапланучы хезмәткәрләргә компенсация түләүләре күләме:

| Бердәм тариф челтәренең түләү дәрәҗәләре | Компенсация түләүләре, сумнарда |
|---|---|
| 1 | 1803 |
| 2 | 1703 |
| 3 | 1613 |
| 4 | 1502 |
| 5 | 1225 |
| 6 | 1200 |
| 7 | 1124 |
| 8 | 1112 |
| 9 | 1112 |
| 10 | 1100 |
| 11 | 1093 |
| 12 | 1093 |
| 13 | 1093 |
| 14 | 1093 |
| 15 | 1093 |
| 16 | 1093 |
| 17 | 1093 |
| 18 | 1093»; |

3) 35 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«35. «Янгын сүндерү – коткару отряды» Яр Чаллы шәһәренең муниципаль бюджет учреждениесе (алга таба – Янгын сүндерү - коткару отряды) җитәкчесенең һәм хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү буенча Бердәм тариф челтәренең тариф коэффициентлары һәм тариф ставклары (окладлары):

| Бердәм тариф челтәренең түләү дәрәҗәләре | Тариф ставкалары (окладлары), сумнарда |
|---|---|
| 1 | 3 358 |
| 2 | 3 515 |
| 3 | 3 660 |
| 4 | 3 836 |
| 5 | 4 259 |
| 6 | 4 725 |
| 7 | 5 191 |
| 8 | 5 707 |
| 9 | 6 265 |
| 10 | 6 879 |
| 11 | 7 527 |
| 12 | 8 140 |
| 13 | 8 791 |
| 14 | 9 447 |
| 15 | 10 193 |
| 16 | 10 948 |
| 17 | 11 794 |
| 18 | 15 111». |

4) 36 пунктның 3 пунктчасында «эшчәнлек нәтиҗәләре буенча премия» сүзләре алдыннан «Башкарма комитет карары һәм учреждениенең локаль акты белән расланган учреждение эшчәнлегенең нәтиҗәлелек критериеләре нигезендә хисапланучы» сүзләрен өстәргә;

5) 54, 55 пунктларны түбәәдәге редакциядә бәян итәргә:

«54. Хезмәткәрләрнең вазифаи окладлары тәшкил итә:

| Вазифа исеме | Вазифаи оклад күләме, сумнарда |
|---|---|
| Директор | 15 173,0 |
| Баш бухгалтер | 12 138,0 |
| Баш икътисадчы | 10 341,0 |
| Баш бухгалтер урынбасары | 8 354,0 |
| Кадрлар буенча белгеч | 6 251,0 |

| | |
|---|---|
| Бухгалтер | 6 251,0 |
| Икътисадчы | 6 251,0 |
| Инженер-программист | 6 251,0 |
| ЭВМ өлкән оператор | 6 081,0 |
| Диспетчер | 5 960,0 |
| Учак дезинфекциясе бүлеге мөдире | 9 185,0 |
| Табиб-эпидемиолог ярдәмчесе | 7 173,0 |
| Инструктор-дезинфектор | 7 173,0 |
| Медицина дезинфекторы | 6 736,0 |
| Профилактик дезинфекция бүлеге мөдире | 9 185,0 |
| Врач-дезинфектолог | 8 748,0 |
| Лаборант | 7 173,0 |

55. Эшчеләрнең хезмәт хакы ставкалары тәшкил итә:

| Вазифа исеме | Вазифаи оклад күләме, сумнарда |
|---|---|
| Махсус киемне юу һәм төзәтү буенча машинист | 6 263,0 |
| Балта остасы | 6 263,0 |
| Биналарны җыештыручы | 6 263,0 |
| Слесарь – сантехник | 6 263,0 |
| Каравылчы | 6 263,0 |
| Автомобиль йөртүче | 6 388,0». |

3. Әлеге Карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2015 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ